ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 2 » апрель 2018 ел** **№ 304**

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 25.03.2013 ел, №385 карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм әлеге вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 25.12.2008 ел, №273-ФЗ Федераль законның 8 статьясындагы 7.1 өлеше, РФ Хөкүмәтенең 13.03.2013 ел, №207 карары нигезендә, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм әлеге вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү кагыйдәләрен раслау турында" карары нигезендә (РФ Хөкүмәтенең 06.11.2014 ел, № 1164 карары редакциясендә) Арча район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында:

Муниципаль учреждение җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар һәм бу вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелә торган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турындагы Нигезләмәдә (25.03.2013 ел, №385 Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган):

а) 1 пунктта «тапшырыла торган» сүзне «тапшырылган" сүзенә алмаштырырга»;

б) 8 пунктның «б» пунктчасында «тапшырыла торган» сүзләрен «тапшырылган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыккан көненнән үз көченә керә (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешентикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин